**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылы торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2022 елның 19 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге Керкәле торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге Керкәле авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлар тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тукай урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-территорияне механикалаштырылган һәм кулдан чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү:

-Керкәле торак пунктында Совет урамы, Җәлил урамы янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру;

4) Ритуал хезмәтләрен һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру:

-Керкәле торак пунктындагы зират территориясендә (килешү буенча түләү) коры һәм чүп үләнен чабу, иске авия хәлендәгеагачларны кисү;

5) Ял вакытын оештыру өчен шартлар тудыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү:

- «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел»бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Совет урамы, 93 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.И.Бигманов